# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О порядке проведения оценки регулирующего воздействия проектов нормативных правовых актов Республики Татарстан и экспертизы нормативных правовых актов Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
11 июля 2019 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 7 марта 2014 года № 14-ЗРТ «О порядке проведения оценки регулирующего воздействия проектов нормативных правовых актов Республики Татарстан и экспертизы нормативных правовых актов Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 3; 2016, № 3) следующие изменения:

1) наименование после слов «проектов нормативных правовых актов Республики Татарстан» дополнить словами «, оценки фактического воздействия»;

2) статью 1 после слов «и порядок проведения» дополнить словами «оценки фактического воздействия и»;

3) в статье 2:
а) в наименовании слова «и экспертиза нормативных правовых актов» исключить;
б) часть 1 изложить в следующей редакции:
«1. Проекты нормативных правовых актов подлежат оценке регулирующего воздействия, проводимой уполномоченным органом исполнительной власти Республики Татарстан в порядке, установленном настоящим Законом, за исключением:
1) проектов законов Республики Татарстан, устанавливающих, изменяющих, приостанавливающих, отменяющих региональные налоги, а также налоговые ставки по федеральным налогам;
2) проектов законов Республики Татарстан, регулирующих бюджетные правоотношения;

3) проектов нормативных правовых актов:

а) устанавливающих, изменяющих, отменяющих подлежащие государственному регулированию цены (тарифы) на продукцию (товары, услуги), торговые надбавки (наценки) к таким ценам (тарифам) в соответствии с федеральными законами, определяющими порядок ценообразования в области регулируемых цен (тарифов) на продукцию (товары, услуги), торговых надбавок (наценок) к таким ценам (тарифам);

б) разработанных в целях ликвидации чрезвычайных ситуаций природного и техногенного характера на период действия режимов чрезвычайных ситуаций.»;

в) часть 3 признать утратившей силу;

4) дополнить статьей $3^1$ следующего содержания:

«Статья $3^1$. **Порядок проведения оценки фактического воздействия нормативных правовых актов**

1. Оценка фактического воздействия нормативных правовых актов проводится регулирующим органом в порядке, определенном Кабинетом Министров Республики Татарстан.

2. Оценка фактического воздействия нормативных правовых актов проводится в целях анализа достижения целей регулирования, заявленных в сводном отчете о проведении оценки регулирующего воздействия, определения и оценки фактических положительных и отрицательных последствий принятия нормативных правовых актов, а также выявления в них положений, необоснованно затрудняющих ведение предпринимательской и инвестиционной деятельности или приводящих к возникновению необоснованных расходов бюджета Республики Татарстан.

3. Заключение об оценке фактического воздействия нормативного правового акта подготавливается уполномоченным органом на основе поступившего от регулирующего органа отчета об оценке фактического воздействия нормативного правового акта.

4. Выводы, отраженные в заключении об оценке фактического воздействия нормативного правового акта, могут служить основанием для формирования уполномоченным органом предложений о внесении изменений в нормативный правовой акт или о его отмене.»;

5) в части 1 статьи 4 слово «определяемом» заменить словом «определенном».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
06 августа 2019 года
№ 64-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау тәртибе турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3; 2016, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
**«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының фактлагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм аларга экспертиза ясау тәртибе турында»**;

2) 1 статьяда «уздыру тәртибен һәм эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген башкару мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларына (алга таба – норматив хокукый актлар)» сүзләрен «, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Республикасы законнарының, Татарстан Республикасы Президенты указларының, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларының, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларының (алга таба – норматив хокукый актлар) фактлагы йогынтысын бәяләүне уздыру һәм норматив хокукый актларга» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2 статьяда:

а) исемендә «һәм норматив хокукый актларга экспертиза ясау» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Норматив хокукый актлар проектларына әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан башкарыла торган җайга салу йогынтысын бәяләү уздырылырга тиеш, моңа түбәндәгеләр керми:

1) региональ салымнарны, шулай ук федераль салымнар буенча салым ставкаларын билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы Татарстан Республикасы законнары проектлары;

2) бюджетка кагылышлы хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы Татарстан Республикасы законнары проектлары;

3) түбәндәге норматив хокукый актлар проектлары:

а) продукциягә (товарларга, хезмәт күрсәтүләргә) җайга салына торган бәяләр (тарифлар), мондый бәяләргә (тарифларга) сату өстәмәләре (өстәмә бәяләр) өлкәсендә бәя кую тәртибен билгели торган федераль законнар нигезендә продукциягә (товарларга, хезмәт күрсәтүләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар), мондый бәяләргә (тарифларга) сату өстәмәләре (өстәмә бәяләр) билгеләүче, үзгәртүче, юкка чыгаручы;

б) табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында гадәттән тыш хәл режимының гамәлдә булу чорына әзерләнгән.»;

в) 3 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ статья өстәргә:

«$3^1$ статья. **Норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләүне уздыру тәртибе**

1. Норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү җайга салучы орган тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә уздырыла.

2. Норматив хокукый актларның факттагы йогынтысын бәяләү җайга салу йогынтысын бәяләүне уздыру турындагы җыелма хисапта күрсәтелгән җайга салу максатларына ирешүне анализлау, норматив хокукый актлар кабул итүнең факттагы уңай һәм тискәре нәтиҗәләрен билгеләү һәм бәяләү, шулай ук аларда эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген алып баруны нигезсез кыенлаштыра торган яисә Татарстан Республикасы бюджетының нигезләнмәгән чыгымнарының барлыкка килүенә китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла.

3. Норматив хокукый актның факттагы йогынтысын бәяләү турында бәяләмә вәкаләтле орган тарафыннан җайга салучы органнан килгән норматив хокукый актның факттагы йогынтысын бәяләү хакындагы хисап нигезендә әзерләнә.

4. Норматив хокукый актның факттагы йогынтысын бәяләү турындагы бәяләмәдә күрсәтелгән нәтиҗәләр вәкаләтле орган тарафыннан норматив хокукый

актка үзгәрешләр кертү турында яисә аны юкка чыгару хакында тәкъдимнәр әзерләү өчен нигез булырга мөмкин.»;

5) 4 статьяның 1 өлешендә татарча текст үзгәрешсез кала.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 06 август
№ 64-ТРЗ